**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№7338**
**15.11.2021**

Муниципаль гарантияләр бирү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм «Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм 2020 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 22 апрелендәге 120-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2019 елның 5 декабрендәге 6323 номерлы карары белән расланган муниципаль гарантияләр бирү тәртибе турында нигезләмәнең 6 пунктының өченче абзацына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) «принципалның финанс хәле» сүзләрен «финанс хәл» сүзләренә алмаштырырга;

2) түбәндәге эчтәлектәге җөмләләр өстәргә: «Принципал күрсәтелгән бурычны үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән очракта, принципал Россия Федерациясе законнарында, муниципаль гарантия бирү турындагы шартнамәдә билгеләнгәнчә җаваплы. Принципалның күрсәтелгән бурычны үтәмәве муниципаль гарантияне үтәмәү (гарантияне үтәү турында бенефициар таләпләрен нигезсез һәм канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип тану), муниципаль гарантияне туктату өчен нигез булып тормый.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов